СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Центральная, д.3, с. Новый Кырлай, Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Үзәк урам, 3 нче йорт, Яңа Кырлай авылы, Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366) 56-7-32, факс (84366) 56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**

**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 19 » октябрь 2020 ел** **№ 8**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2020 елның 11 сентябрендәге 105 номерлы «Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрләргә һәм пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга бер тапкыр акчалата түләү турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2020 елның 11 сентябрендәге 105 номерлы «Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрләргә һәм пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга бер тапкыр акчалата түләү турында" карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 3 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3) "Иминият пенсияләре турында" 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - "Иминият пенсияләре турында" Федераль закон) нигезендә картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясен билгеләү;

2) 2 нче кушымтаның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү(алга таба - бер тапкыр бирелә торган акча)тәртибе турындагы Нигезләмә 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында кодексы, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнде."

3) 2 нче кушымтаның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирү яшенә җиткәч яисә «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә инвалидлык буенча пенсия билгеләнгәндә һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы

булганда,муниципаль хезмәткәрнең гаепле гамәлләренә бәйле эштән азат ителүенән тыш, муниципаль хезмәттән азат ителү аңлашыла.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров